МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

№ 1030 17.12.2018

***Постановление*** ***Карар***

Суд тарафыннан хокукка яраксыз
яки хокукка яраклылыгы чикләнгән
дип табылган балигъ булган
гражданнарга карата опека һәм
попечительлек өлкәсендә дәүләт
хезмәтләре күрсәтүнең яңа
редакциядәге административ
регламентын раслау турында

2010 елның 27 маенда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карары нигезендә, Чистай шәһәр прокуратурасының 2018 елның 27 ноябрендәге “Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен көйләүче муниципаль норматив-хокукый актларны тикшерү нәтиҗәләре турында”гы 02-01-16-2018нче номерлы мәгълүматы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының норматив-хокукый актларын гамәлдәге закон нигезендә тәртипкә китерү максатында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының суд тарафыннан хокукка яраксыз яки хокукка яраклылыгы чикләнгән дип табылган балигъ булган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә расларга:

- опекага алынганнарны стационар хезмәт күрсәтү өчен психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында карар бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (1нче кушымта);
- суд тәртибендә хокукка яраксыз яки хокукка яраклылыгы чикләнгән дип табылган балигъ булган гражданнар өстеннән опека һәм попечительлекне гамәлгә кертү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (2нче кушымта);
- опекага алынганнар мәнфәгатендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (3нче кушымта);
- хокукка яраксыз балигъ булган зат мәнфәгатендә опекунга торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (4нче кушымта);
- опекага алынганныкы булган торакны наймга бирү буенча опекунга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (5нче кушымта);
- опекага алынганнар мөлкәте белән сделкалар ясауга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (6нчы кушымта);
- опекунга, урынын алыштыру сәбәпле, опекага алынганны яшәү урыны буенча теркәлү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (7нче кушымта);
- опекунга яки попечительгә опекага алынучының мирас хокукына керүенә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (8нче кушымта);
- опекунга яки попечительгә опекага алынучының җыелган акчасы счетыннан файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (9нчы кушымта);
- стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда булган хокукка яраксыз гражданнарны даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру турындагы нәтиҗәне бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүенең административ регламенты (10нчы кушымта);

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 05.06.2018 елгы “Яңа редакциядәге суд тарафыннан хокукка яраксыз яки хокукка яраклылыгы чикләнгән дип табылган балигъ булган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 431 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының опека, попечительлек һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны һәм күзәтүчесезлекне кисәтү буенча бүлегенә (С.А. Сударкинага) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Х. Кәшәповага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов